КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче
Өч Нарат торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

22.11.2023 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2023 нче елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2024 нче елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Өч Нарат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

– Өч Нарат авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 76 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 42 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның 42 е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Иске Икшермә авыл җирлегенең Өч Нарат торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2024 нче елда Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Өч Нарат авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;" дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче:

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин